СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2022 Баулы шәһәре №150

2023 елга һәм 2024-2025 еллар
план чорына Баулы муниципаль
районының социаль-икътисадый
үсешенең төп күрсәткечләрен
фаразлау турында

Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары Э.И. Галимовның «2023 елга һәм 2024-2025 елларның план чорына Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләрен фаразлау турында» докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Баулы муниципаль районы Советы, Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, шәһәр хезмәтләре һәм төрле милек формасындагы предприятиеләр белән берлектә, 2022 елда районның социаль-икътисадый үсешен халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлтелгән билгеле бер эш башкарылуын билгеләп үтә.

2022 елда Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең төп параметрларына анализ түбәндәге бәяләү нәтиҗәләрен күрсәтте:

- тулай территориаль продукт 61,2 млрд. сум тәшкил итәчәк;
- төп капиталга инвестицияләр - 4,5 млрд. сум;
- авыл хуҗалыгы продукциясе күләме - 3,2 млрд. сум;
- җитештерелгән һәм җибәрелгән продукция, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр күләме 12,6 млрд. сум тәшкил итәчәк.

Шәһәр һәм район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре тарафыннан халыкка 459,4 млн. сумлык түләүле хезмәтләр күрсәтеләчәк. Ваклап сатуда товар әйләнеше 5,4 млрд. сум тәшкил итәчәк.

2022 елда Баулы муниципаль районы үсешенең әйтеп үтелгән параметрларыннан һәм тенденцияләреннән чыгып, Баулы муниципаль районының 2023 елга һәм 2024-2025 елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы формалаштырылды.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елга социаль-икътисадый үсешнең якынча нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).

2. Баулы муниципаль районының 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешенең төп параметрларын расларга (2нче кушымта).

3. Барлык милек формаларындагы сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- 2023 елга һәм 2024 - 2025 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен үтәүне тәэмин итәргә;

- эшчәнлекне җитештерү куәтләрен нәтиҗәле файдалануга, хезмәт шартларын яхшыртуга һәм эшләүчеләрнең сәламәтлеген саклауга, хезмәт хакын вакытында түләүгә юнәлдерергә, эш урыннарын кыскартуга юл куймаска;

- хезмәт хакын арттыру чараларын күрергә һәм аның дәрәҗәсенең минималь куллану бюджеты күләменнән түбәнрәк төшүгә юл куймаска.

4. Баулы муниципаль районы башкарма комитетына:

- халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуга тырышлык куеп, муниципаль районның комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итәргә;

- мөмкинлекләр һәм икътисадый үсеш перспективалары кысаларында бюджет челтәрен оптимальләштерү, энергияне сак тоту һәм энергия чыганакларын киметү, социаль өлкә, торак-коммуналь хуҗалык тармакларында бюджеттан тыш юнәлешләрне үстерү чараларын күрергә.

5. Әлеге карарны Баулы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе И.И. Гузаиров

Татарстан Республикасы
Баулы район Советының
2022 елның _______ «____»
номерлы карарына
1нче кушымта

# 2022 елның узган чорында Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2022 елда Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең көтелгән нәтиҗәләре

| Күрсәткечләр | 2022 гыйнвар-июнь | 2022 бәя |
|---|---|---|
| I. Макроикътисад күрсәткечләре | | |
| 1. Тулаем региональ продукт (төп бәяләрдә), млн. сум | - | 61198,4 |
| 2. Җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәтләр) күләме, млн. сум. | 6632,1 | 12598,1 |
| 3. Сәнәгать производствосы индексы, алдагы елга %ларда | 105,7 | 102,1 |
| 4. Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, млн. сум | - | 3212,3 |
| 5. Финанслауның барлык чыганакларыннан инвестицияләр күләме (төп капиталга) млн. сум | 2709,8 | 4990,2 |
| 6. Торак йортларны файдалануга кертү, мең кв. м | 5,9 | 15,0 |
| 7. Кече һәм урта предприятиеләр әйләнеше, микропредприятиеләрне дә кертеп, млн. сум. | | 2866,8 |
| 8. Хезмәт хакы фонды, млн. сум | 1761,9 | 3790,7 |
| 9. Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына), мең кеше | 0,92 | 0,6 |
| 10. Икътисадый актив халыкның гомуми санында эшсезләр өлеше, % | 0,51 | 0,33 |
| II. Тормыш дәрәҗәсе | | |
| 1. Халыкның җан башына керемнәре, уртача айга, сум | 32710,6 | 34840,2 |
| алдагы елга % ларда | 117,8 | 113,5 |
| 2. Уртача айлык хезмәт хакы (елда уртача), сум | 46134,9* | 42544,9 |
| алдагы елга % ларда | 117,2 | 106,7 |
| III. Сәнәгать | | |
| Сәнәгать продукциясенең мөһим төрләрен җитештерү: | | |
| Нефть, млн.т. | 1,1 | 2,0 |
| IV. Агросәнәгать комплексы | | |
| 1. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | - | 78,0 |
| Ашлык (эшкәрткәннән соң үлчәмдә), мең тонна. | - | 30,0 |
| Ит (терлек һәм кош тере үлчәмдә), мең тонна. | 0,757 | 1,526 |
| Сөт, мең тонна | 6,49 | 13,6 |
| V. Кулланучылар базары | | |
| 1. Ваклап сату әйләнеше, млн. сум. | 3167,9 | 5437,6 |
| 2. Халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү күләме, млн. сум | 193,1 | 459,4 |

*МСПны исәпкә алмыйча

Татарстан Республикасы
Баулы район Соетының
2022 елның _______ «____»
номерлы карарына
2нче кушымта

Баулы муниципаль районының 2023 елга һәм
2024 һәм 2025 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеше
ФАРАЗЫ

| Күрсәткечләр | 2023 фараз | 2024 фараз | 2025 фараз |
|---|---|---|---|
| I. Макроэкономические показатели | | | |
| 1. Тулаем региональ продукт (төп бәяләрдә), млн. сум | 64747,9 | 69021,3 | 73024,5 |
| 2. Җибәрелгән продукция (эшләр, хезмәтләр) күләме, млн. сум. 3. Сәнәгать производствосы индексы, алдагы елга %ларда | 13174,4 | 13727,7 | 14427,8 |
| 3. Сәнәгать производствосы индексы, алдагы елга %ларда | 101,3 | 101,5 | 102,2 |
| 4. Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, млн. сум | 3376,1 | 3521,3 | 3711,5 |
| 5. Финанслауның барлык чыганакларыннан инвестицияләр күләме (төп капиталга) млн. сум | 4638,4 | 4898,8 | 5075,2 |
| 6. Торак йортларны файдалануга кертү, мең кв. м | 15,0 | 15,0 | 15,0 |

| Күрсәткечләр | 2023 фараз | 2024 фараз | 2025 фараз |
|---|---|---|---|
| 7. Кече һәм урта предприятиеләр әйләнеше, микропредприятиеләрне дә кертеп, млн. сум. | 3153,5 | 3297,0 | 3533,2 |
| 8. Хезмәт хакы фонды, млн. сум | 4211,5 | 4573,7 | 4953,3 |
| 9. Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына), мең кеше | 0,8 | 0,8 | 0,8 |
| 10. Икътисадый актив халыкның гомуми санында эшсезләр өлеше, % | 0,45 | 0,45 | 0,45 |
| II. Тормыш дәрәҗәсе | | | |
| 1. Халыкның җан башына керемнәре, уртача айга, сум | 34610,5 | 36756,4 | 38741,3 |
| алдагы елга % ларда | 105,8 | 106,2 | 105,4 |
| 2. Уртача айлык хезмәт хакы (елда уртача), сум | 46995,17 | 51187,55 | 55540,54 |
| алдагы елга % ларда | 110,4 | 108,9 | 105,8 |
| III. Агропромышленный комплекс | | | |
| 1.Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | | |
| Ашлык (эшкәрткәннән соң үлчәмдә), мең тонна. | 80,0 | 81,0 | 82,0 |
| Ит (терлек һәм кош тере үлчәмдә), мең тонна. | 1,60 | 1,61 | 1,62 |
| Сөт, мең тонна | 13,7 | 13,9 | 14,0 |
| | | | |
| IV. Кулланучылар базары | | | |
| 1. Ваклап сату әйләнеше, млн. сум. | 6142,2 | 6668,5 | 7150,1 |
| 2. Халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү күләме, млн. сум | 485,2 | 511,4 | 527,3 |